Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге башлыгы

КАРАР

14 ноябрь, 2022ел. № 6

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Яңа Ибрай авыл җирлегендә
гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм алардан файдалану
мәсьәләсе буенча гражданнар
җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 ел, 28 июль, 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районының «Яңа Ибрай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 ел, 25 ноябрь, 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Аксубай районы Яңа Ибрай авылы Совет урамы, 5 нче йорт адресы буенча урнашкан Яна Ибрай авыл клубы Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлегенең Яңа Ибрай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенын билгеләргә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, беренче төркем инвалидлардан, сугыш ветераннарыннан һәм көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, 400 сум күләмендә 2023 елда үзара салым кертү һәм алдагы эшләрне башкару буенча әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

**Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;**

- Яңа Ибрай авылы урамнарына вак таш сатып алу;

- Яңа Ибрай авылы юлларын тигезләү;

- Яна Ибрай авылында кышкы чорда автомобиль юлларын карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, урамнарны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда белдерү такталары һәм стендларда урнаштыру юлы белән, шулай ук Аксубай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

Аксубай муниципаль районы
Яңа Ибрай авыл
җирлеге башлыгы: Ф. Х. Кәбиров